| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

№ 4/4 «17» декабрь 2020 ел

Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә
чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата
бүләкне түләү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендәге 40/1 номерлы карарына, коррупциягә каршы экспертиза нигезендә, Чүпрәле районы прокурорының 2020 елның 16 декабрендәге 02-01-16/2020 номерлы таләпләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының «Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләкләүләр, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 26 апрелендәге 28/1 номерлы карары белән расланган 12 кушымта «Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе һәм шартлары» тәртибенең 1 пунктына (2018 елның 27 маендагы 29/1 номерлы 2018 елның 11 сентябрендәге 32/1 номерлы; 2018 елның 14 ноябрендәге 36/2 номерлы; 13.11.2020 ел, № 3/4 редакциясендә) - «муниципаль вазыйфа биләүче затның эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.» сүзләрен төшереп калдырып үзгәрешләр кертергә.

2.Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегенең рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге башлыгы: И.И.Якупов